**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Уразлы авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**"18" сентябрь 2018 ел** **№ 82**

**Җирле референдум үткәрү инициативасы турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокуклары һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 17 статьясы, Кама Тамагы районы Уразлы авыл җирлеге Уставының 15 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы районы Уразлы авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

**1.** Татарстан Республикасы Кама Тамагы районы Уразлы авыл җирлеге территориясендә түбәндәге мәсәлә буенча җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыкты:

"2019 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Уразлы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум үзара салым кертү белән килешәсезме, һәм җыелган акчаларны, киләсе эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә куллану белән килешәсезме:

**- Жирлек территорияси эчендә чисталыкны өештрыү**;
*** Күмү урыннарын карап тору;**

*** Җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

**“ӘЙЕ** **ЮК”**

2. Әлеге карарны адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерү:
1) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Уразлы авылы, Тынычлык урамы,7;

2) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Кече Карамал авылы, Кече урамы, 1;
шулай ук Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

“Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Уразлы авыл җирлеге”
башлыгы, “Татарстан
Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы
Уразлы авыл җирлеге”
Советы рәисе М.Г.Хәмидуллин